| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Большенуркеевского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского муниципального**<br>**района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль**<br>**районынын Зур Нөркәй**<br>**авыл җирлеге**<br>**Советы** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 14 сентябрь № 48

Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгару тәртибе турында» 2007 елның 10 маендагы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 343-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм алып китү тәртибе турында» 2007 елның 10 маендагы 9 нче нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2 нче бүлекнең уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Калдыкларны урнаштыру объектлары - калдыкларны, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану калдыкларын урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар (1992 елның 21 февралендәге N 2395-I номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә файдаланылырга тиешле ачылган һәм урнашкан тау токымнарын саклау объектларыннан тыш) һәм калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын үз эченә алган махсус җиһазландырылган корылмалар;»

2. Әлеге карар 2023 елның 1 сентябрендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Советы рәисе Р.М.Гайсин